

26 апрельдә боек шагыйребез Габдулла Тукайнын туган конендә, татар халкы Туган тел конен билгеләп vтә. Альфия Нургаян кызы Маланьчева, Мордовия Республикасы А.С.Пушкин исемендәге милли китапханәнен туган телне һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлегенен баш китапханәчесе житәкчелегендә, Пушкинканын 2 меннән артык булган китаплы татар әдәбияты секторында Саранскнын 11 һәм 38, Ләмберәнен беренче урта мәктәпләре катнашы белән Туган тел һәм Габдулла Тукай турында матур чара vтте.

Башка бәйрәмнәр һәм истәлекле даталар белән беррәттән, бу кон һәркайсыбызнын кvнелендә аерым урын биләп тора. “Туган теленне онытсан, рухынны югалтырсын…”– дип язган шагыйрь. Туган телен белмәгән кеше vз халкыннан да, милли тамырларыннан да аерыла, туган жиренә дә ят була. Без кvпмилләтле илебездә торле телләрнен һәм vзенчәлекле диалектларнын байлыгын һәм а



һәнен саклап калырга тиешбез. Туган тел конен һәрвакытта да тынычлык, дуслык һәм татулык бәйрәме дип кабул итәбез. Һәм чынлап та татар, рус, мордва милләтле балалар татар һәм рус телләрендә Габдулла Тукай һәм анын турында язган шигырьләрне яттан сойләделәр, укыдылар. Био- графиясенә сәяхәт иттек, презентация карадык, матур жырлар башкардылар.
Чакырылган барлык кунаклар да кичәдә актив катнаштылар. Чарада Саранск шәһәренен рухи-мәдәни vзәге директоры Фатих Исхак улы Шафиев һәм «Юлдаш» ижтимагый-сәяси газетасыхәбәрчесе Наилә Халил кызы Насырова катнашты; алар республика татарлары очен башкарган эшләре турында, ә Ләмберәнен 1нче мәктәбе татар теле укытучысы Алмаз Кериш кызы Янгляева мәктәптә татар телен укыту турында сойләделәр.
Ләмберәнен беренче мәктәбе 7Б сыйныф укучысы Айлина Янгляева Габдулла Тукай тормышы турында доклад ясады. Шул ук уку йортынын 6Б сыйныф укучысы Диляра Сюбаева, укытучы-организатор Зульфия Захир кызы Сюбаева житәкчелегендә, Саранск шәһәре №38 мәктәбе 4А сыйныф укучысы Даша Блинникова, укытучы




сы Ольга Дмитриевна Абрамова житәкчелегендә матур жырлар башкардылар. Зал да кушылды.
Сәнгатьле шигырьләр укучыларны - Амина Азисованы, Ильнар Грошевны, Радмир Серебряковны, Элина Ряхмятуллованы, Валерия Малышеваны, СулейманШафиевны, Рената Шакаеваны, Вика Баландинаны Ләмберә 1нче мәктәбендә татар теле укытучысы Янгляева Алмаз Кериш кызы әзерләп алып килгән. Укытучы vзе дә чарада актив катнашты.
Малика Чуракованы, Аиша Янгличеваны Саранск шәһәре 11нче мәктәбенен башлангыч сыйныфларында татар теле укытучылары Земфира Хафиз кызы Мангутова белән Юлия Рәшит кызы Рамазанова әзерләгәннәр.
Пушкинканын туган телне һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге хезмәткәрләре чарага «И туган тел, и матур тел!» китап кvргәзмәсе һәм шул ук исемдәге презентация Габдулла Тукайнын тормышы, ижаты һәм татар теле турында материаллар тупланган иде.
Матур кичә бергәләп фотога тошv белән тәмамланды.

**Наилә НАСЫРОВА**